МАОУ СОШ №4

# Наше Время!
# Безнең Вакыт!


ВЫПУСК №1 ОКТЯБРЬ



















## Рәхмәт сиңа, Укытучым!

Укытучы… Бүген галим дә, ташчы да, иген итүче дә олы исемең алдында баш ия, чөнки теләсә кайсы һөнәргә юл башы синең фидакар - хезмәтең нәтиҗәсен-дә салына. Син дөньядагы барлык уңай сыйфатларны үзеңә туплагансың. Киң күңеллелек, тырышлык кешеләргә чиксез мәхәббәт… Синдәге сабырлык аналар сабырлыгына тиң. Юкка гынамы сине әниләребез белән тиңлибез. Шушы катлаулы чорда да көндәлек мәшәкатьләрне бер






Вместо тысячи слов....

читкә куеп, башка-лар өчен яшисең. Авыр, ләкин дөнь-ядагы иң кирәкле хезмәтне бар көчеңне куеп башкарасың. Нарасый күңеленә син чәчкән игелек орлыклары шытымнар бирсен, үссен, корымасын иде. Укытучы! Бәйрәмең белән сине! Уңышларыңа сөенеп, бәхет хисе кичереп яшә. Һәр таңны сау-сәламәт каршыла. замана авырлыклары, күңел төшенкелеге киләчәктә сине читләтебршк үтәргә тырышсын.

Яхшы укытучыларның укучылары да яхшы.

(М.В. Остроградский)

## Школа празднует день педагога!

### Праздник мудрости, знаний труда.

*День учителя — праздник всех, кто связал свою жизнь с образованием. Он уже имеет историю, поскольку впервые был учрежден 29 сентября в 1965 году. Потом его отмечали в первое воскресенье октября. В настоящее время он имеет установленную дату — 5 октября. Учитель – профессия, имеющая тысячелетнюю историю, одна из самых уважаемых и ценимых в обществе. Ведь учитель — человек, который с самого раннего детства находится рядом, помогает узнать новое, раскрыть способности, найти свой путь. Педагог первым замечает и первые успехи, и первую любовь. Они работают с годова-лыми малышами детского сада, подростками, студентами, и даже с теми, кто, уже имея стаж, хочет повысить квалификацию.*

*День учителя – праздник, когда стихи и песни звучат для всех воспитателей, педагогов, наставников, тренеров и других людей, чья профессия — образование и развитие других. В этот день можно позвонить первой учительнице, подарить цветы, конфеты классному руководителю. Школьники особенно радуются этому празднику, ведь еще одной его традицией является такой веселый день самоуправления!*






# Минем һөнәрем - Укытучы!



**1990 елда Минзәлә Педучилищесын татар бүлеген бетереп эшкә килдем. 4-нче мәктәпкә мине Рамиль Марванович алды. Шуннар бирле бу мәктәптә укытам. Быел алтынчы тапкыр беренче сыйныфларны алдым. Тагы шунысы кызыклы: бу елны үзем укытып чыгарган укучым, Хасаншина Эльвираның малае үземә укырга килде.**

**Балаларны, эшемне бик яратам!**













# Без 1"А" сыйныф укучылары!





## “Иң гүзәл кеше икәнсез”

Мин-Шәйхетдинова Инзиля 1А сыйныф укучысы. Минем укытучы—Лилия Котдусовна. Аны бик яратам һәм хөрмәт итәм, чонки ул безгә әйбәтләп аң-лата; чиста, матур итеп язарга; хәреф танырга;укырга; дәрестә дөрес утырырга. Мин Лилия Котдусовнаны укытучылар көне белән котлыйм. Ана сәламәтлек, сабырлык, эшендә уңышлар телим.

Хәбәрче—
Пинакова Софья



Спецкор ШГ взяла интервью у учителя начальных классов— **Аглямовой Эльзы Мирсаяфовны**

**1.Мәктәптә укыганда сезгә нинди фәннәр ошый идее? - әдәбият**

**2.Кечкенә вакытта кем булырга хыяллана идегез? - әлбәттә укытучы!**

**3.Укытучының иң мөһим сыйфаты? - балаларны ярату.**

**4.Хезмәттәшләр арасында кемне идеал укытучы дип атар идегез? - Һәр укытучының яхшы һәм тискәре яклары да бар!**

**5.Яңа кертелгән программаны искечә караганда яхшы дип уйлысызмы?- Юк**

**6.Укытучы профессиясе сезнең өчен хезмәтме, әллә тормышмы?- Тормыш!**

**7.Дәрес вакытында нинди проблемалар белән очрашасыз? - Балаларны кызыксындыру!**

**8.Безнең газетада яңа рубрика булуын теләр идегезме? - Әйе! «Котлыйбыз!»**

**Рәхмәт, сезгә,**
**рәхмәт чын күңелдән,**
**Безне балагыздай күргән өчен,**
**Безнең хисләр белән янып яшәп,**
**Күңелләргә шатлык биргән өчен.**

**4Г сыйныф укучылары**

# “Рәхмәт сезгә.”































# Юбилей!



**В то время, когда росла Сария Хамисовна, большого выбора профессии не было. Те, кто хорошо учились в школе, могли пойти учиться либо на учителя, либо на врача. Выбор Сарии Хамисовны пал на профессию учителя. Как вспоминает Сария Хамисовна, ей нравился процесс преподавания, в детстве она часто играла в школу, используя подручные средства как школьные принадлежности. На такой выбор профессии, как говорит Сария Хамисовна, также могло повлиять то, что ее двоюродная сестра была учителем русского языка и иногда она приносила ей на проверку тетради учеников.**

**О своем первом рабочем дне теперь уже вспоминает как о тяжелом, но пройденном испытании. Раньше, когда учились в пединституте, на работу направляли, не было возможности выбора, где и кем работать. Сарие Хамисовне попалась школа в Заиснком районе деревне Пенячи. Первый рабочий день шокировал. На всю школу было сорок учеников с 1-9 классы включительно. Во всех классах было разное количество учеников, где-то пять, а где-то и вовсе один ученик. В школе преподавался немецкий язык, и так как ставка не набиралась, добавляли еще и русский язык. Сария Хамисовна считает, что ей ближе английский язык, и поэтому работа с другими языками ее не очень вдохновляла. Отработав три года в деревенской школе и приехав в город, Сария Хамисовна продолжила свою рабочую деятельность, но уже с нуля. Она устроилась в школу, где было тысяча учеников, по тридцать учеников в классе. Конечно же, было нелегко перейти от одного ученика в классе к тридцати, а то и большему их количеству. Тяжелым и болезненным также был переход нашей школы от русской к татарской. Во-первых, коллектив был очень хорошим. Были учителя разных национальностей: русские, татары, украинки. Было как-то веселее. Учителя и ученики были против такого перехода, ходили в мэрию, ГУНО, но это не дало положительных результатов. Коллектив был очень хороший, но так как школа перешла из русской в татарскую, многим учителям и ученикам пришлось покинуть ее. Сейчас сложился новый коллектив, школа растет, развивается, принимаются новые методики в образовании. Наша учительница относится к ним положительно и активно применяет их, но все же считает, что старые методики были успешнее и эффективнее.**

**Мы поздравляем Сарию Хамисовну с 55-летним юбилеем. Желаем счастья, успехов, благополучия и исполнения всех желаний!**

**Корреспондент газеты Каримова Резеда, 10А**

Учителя, учителя...
Профессий нет добрей!
Стоите твердо у руля,
Открыв ребенку дверь.
Учитель - самый верныйдруг,
Не выдаст, не предаст;
А если что случится вдруг,
Он руку всем подаст.
Как напряженен этот труд:
Пойми и научи.
Всегда к учителю идут
Студенты и врачи...

Зайдете в светлый класс когда,
Не замечать нельзя
Такие милые всегда,
Усталые глаза.
О, как отважен этот труд:
Задиры, шалуны...
Порой в глаза упрямо лгут.
Вы их понять должны.
Учителя, учителя...
Профессий нет добрей!
Стоите твердо у руля,

**Говорят, что дети - это цветы жизни. Вы помогаете этим цветам расцветать яркими красками, высвобождаете их потенциал, воспитываете из них Людей с большой буквы. Так пусть Ваше добро и теплота возвращаются Вам сторицей! С днём учителя, наши дорогие и любимые учителя!**



**Дорогая Диляра Харисовна!**
**Вы для нас человек, к которому мы всегда можем обратиться за советом и поддержкой. Оставайтесь такой же чуткой к нашим проблемам и радостям. На Вашу заботу и внимание мы всегда будем отвечать своим доверием и любовью. Большого Вам счастья и здоровья. Мы ценим Вас.**
**10А класс**









**Рәхмәтемнең иң олысы,**
**сиңа булсын ветеран -**
**укытучым!**

**Җыерчыклар күбәйсә дә йөзегездә**
**“ Күзлек көче “ кирәксә дә күзегезгә**
**Яшьлек дәрте һич сүрелми эшегездә**
**Шуңа күрә картаймыйсыз үзегез дә**













**Ничә язлар үткән ничә көзләр**
**Бураннары көчле булгандыр**
**Узган еллар сезнең чәчегезгә**
**Көмеш бәсләр булып кунгандыр.**





## “Каурый каләм” түгәрәге җитәкчесе Шигапова А.Р.

### Укытучы хезмәте.

Укытучы... Нинди тирән мәгънәгә ия булган сүз.Укытучы хезмәте – мәңге картаймас шатлык чыганагы. Укытучы кем соң ул? Балаларга аң-белем бирүчеме?Укытучы –иң беренче чиратта, ул бала күңеленә яхшылык, рәхимлек, сафлык, иман орлыкларын салучы, дип уйлыйм мин. Сабырлык, тырышлык, белем таләп итә торган һөнәр –укытучы хезмәте. Сабый бала тормыш ваклыклары арасында югалмасын өчен, юл өйрәтеп, хәреф танытучы иң беренче кеше –укытучы. Укытучы – иң мөһим һәм иң кирәкле һөнәрләрнең берсе.Аларның хезмәте авыр,катлаулы,җәмгыятькә күп файда китерә торган. Бу дөньяда нинди генә биеклекләргә ирешсәк тә, уңышларыбызның  башында укытучы тора.Әйе,нәкъ менә алар безне хәреф танырга,укырга һәм язарга өйрәттеләр, тәрбия-ле,иманлы булырга өндәделәр. Замана күзлегеннән чыгып кара-сак,укытучы һөнәре җиңел түгел.Ләкин үз эшеңне яратып баш-карсаң, һәр иртәдә ашкынып  мәктәпкә килсәң, балаларның зур ышаныч белән сиңа төбәлгән карашларын күрсәң, барлык арулар югала, дип уйлыйм мин, һәм хезмәтеңнән кәнагәтьләнү тойгысы, шатлык хисләре чолгап аладыр.

Үз эшеңне яратып башкару ничек кенә авыр булмасын, ул үзе зур бәхет бит.Минутлар,сәгатьләр,айлар күз ачып йомган арада бор-чулары, шатлыклары  белән бик тиз үтеп китәләр.Укытучы  үзе укыткан укучылары белән саубуллашу вакыты житә. Очар кош-ларын очырган кебек тоя ул үзен. Шул вакытта шатлык һәм гору-рлык хисләре уяна укытучыда. Алар зур тормышка аяк басып,туры юлдан китәрләр, дип ышанып кала.

Укытучы, минемчә, зур,матур,хуш исле гөл. Һәр көнне гөл,укыту-чы күңеле кебек үсә һәм зурая. Гөлнең эше күп: җирдән су алып,үзен ашатырга,кояшка омтылып,яктылыкны йотарга,тәнен җиргә биреп,балаларын үстерергә тели. Укытучы да  бар күңе-лен,көчләрен,бар вакытын безгә-укучыларына багышлап,җиребездә яши.

“Һәр йөрәккә кереп урнашасыз,
Исемегез һәркем телендә.
Беркайчан да болыт капламасын,
Кояш булсын тормыш күгендә”.

Вәлиәхмәтова Ландыш,9а сыйныфы укучысы

**Рәхмәт сезгә!**

**Әле кайчан гына тәүге тапкыр
Ишегең ачтым,туган мәктәбем,
Күңелләрдә шатлык хисе ташый,
Ә кулларда дәфтәр –китабым.
Укытучы апам каршы алды,
Нур бөркелде аның йөзеннән.
Укуга дәрт,тәнгә куәт тулды
Безгә әйткән тәмле сүзеннән.
Безнең кебек бик кыюсыз гына,
Башлагандыр күпме сабыйлар.
Туры юл күрсәтеп белем бирә
Укытучы апа-абыйлар.
Мөгаллимнәр әйдәп бара безне,
Фәннәр диңгезендә йөзәбез.
Тормыш дәрьясында батмас өчен
Белем орлыкларын җыябыз.
Сабыр,тыйнак укытучыларым,
Изге теләгемне җиткерәм:
Һәммәгезгә саулык,бәхет телим,
Чын йөрәктән рәхмәт белдерәм!**

**Дустбобоева Фирүзә, 7в сыйныфы укучысы,4 нче мәктәп.**

**Көн дә шулай аяз күктәй
Кояш кебек елмаеп,
Каршы ала безне көтеп
Яраткан укытучыбыз.
Кыңгырау тавышы белән
Дәресебез башлана.
Укытучы салмак кына
Яңа тема аңлата.**

**Бабичева Лилия,6а**

**Бик тә,бик тә яратам мин
Азалия Рәсимовнаны.
Ул да яратсын дисәгез,
Үпкәләтмәгез аны!
Әйткән сүзен тыңлагыз,
Ул әни кебек кеше
Үзе бәләкәй  булса да,
Бик дәү эшләгән эше.**

**Хашитова Ләйлә,7в сыйныф укучысы.**

**Икенче әниебез.**

Икенче әниебез бар,
Ул мәктәптә укыта.
Мәктәпне бетергәннән соң
Институтка озата.
Укытучы төрле була,
Усалы да бар төсле.
Укытучы усал булса,
Яхшырак булыр төсле.
Укытучыма телим мин
Иң изге теләкләрне.
Көннәр-төннәр йокламый ул,
Тырыша безнең өчен.

**Бикбаева Алия,6а**

**Кадерле укытучым,
Без сезне яратабыз.
Һәр көнне сөенешеп,
Мәктәпкә ашыгабыз.
Сез безгә белем биреп,
Дөньяда юл күрсәтеп,
Дусларны дус итәргә
Яхшылыкка өйрәтеп.
Сез безгә бу тормышта
Булдыгыз бик зур терәк
Яратып сезгә һәрчак
Калабыз бәхет теләп.**

**Сабирова Миләүшә,7в**



**Ваш опыт, знанье, щедрость и участье**
**Оставят в душах наших добрый след.**
**Слагается учительское счастье**
**Из наших ученических побед.**















